СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел. №2**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында Түбән Мәтәскә авылы, Үзәк урам, 22 йорт, Түбән Мәтәскә авыл клубы адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 09 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында Түбән Мәтәскә авылы, Яшьләр урамы, 11 йорт, Түбән Мәтәскә урта гомуми белем бирү мәктәбе адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 09 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Үзәк, Тынычлык, Киров, Мәктәп, Татарстан урамында яшәүчеләр

2нче этап: Комсомол, Тукай, Түбән, Арчабаш, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, Бөек Ватан сугышында катнашканнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә

үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

**1.Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-- Ибраһимов урамыннан (Күпербаш авылы) Яңа урамга һәм Арчабаш урамына кадәрге арада чокырларны ремонтлау.

**1. Күмү урыннарын карап тоту**

Түбән Мәтәскә авылы зираты коймасын ремонтлау һәм зиратның тирә-ягын төзекләндерү эшләрен төгәлләү.

**2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- Түбән Мәтәскә авылында скважина өчен насос алу-1 данә.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына: ТР, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай урамы, 2 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ